# Мәктәп хәбәрчесе

**№3 (№16) март-май 2020 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе гәзите*

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


*/Мөхәррир сүзе /*



## *Замана афәтеннән сакланыйк*

Быелгы уку елының соңгы чиреген моңарчы күрелмәгән шартларда тәгәлләргә туры килә. Кайчандыр безгә кадәр килеп җитмәс тоелган авыру арабызда булуы мөмкин икәнлекне барыбыз да аңладык. Чир дөньябызны күз ачып йомган арада шулкадәр үзгәртте ки: бүген беркем дә вируснының киләчәктә үзен ничек күрсәтәчәген, халыкка нинди сынаулар әзерләвен тәгаен әйтеп бирә алмас. Барыбыз да бу сынауларны баштан кичердек: озак вакыт кеше арасына чыга алмыйча, укырга килә алмыйча өйләргә бикләндек. Хәтта бу чор күп нәрсәнең кадерен белергә өйрәтте сыман.

Тиз генә үтәр кебек булган коронавирус һаман бирешергә уйламый: кыйтгаларны яулавын дәвам итә. Бар дөнья галимнәренең бу эшкә җиң сызганып тотынуы – вирусның никадәр катлаулы һәм куркыныч булуын күрсәтә.

Ковид-19 – вируслы чир һәм ул, нигездә, кешенең сулыш алу системасын зарарлый. Бер сүз белән әйткәндә, ул–авыр кискен респиратор инфекция. Алар ОРВИ формасында, җиңелрәк формада да үтәргә дә, шул ук вакытта вируслы үпкә ялкынсынуы белән катлауланырга да мөмкин. Моның исә үлемгә китерүе бар.

Авыру, нигездә, һава-тамчы һәм контакт юлы белән тарала: ютәл, төчкерү, кочаклашу – чир таралуга сәбәпче була ала. Вирус төрле төрле өслекләрдә дә күпмедер яши ала. Мәсәлән, пластмассада аның 72, катыргыда 20 сәгатьтән кимрәк “яшәве билгеле. Таҗлы вирус авыруы, тәү карашка, ОРВИ һәм грипп белән охшаш. Чирләүчеләрдә югары тән температурасы, тын алу авырлашу, баш авырту һәм бар тәндә хәлсезлек, борын тыгылу, ютәл һәм төчкерү, мускуллар авырту, тән изелү, күңел болгану һәм косу билгеләре күзәтелә.

Чирнең инкубация чоры 4-14 көн. Әгәр үзегездә бу билгеләрне тоясыз, җитмәсә, Covid19 киң таралган җирләрдән йөреп кайткансыз, шулай ук бу чир белән авыручы кешеләр белән бәйләнештә булгансыз икән, һичшиксез, йортыгызда үзизоляцияләнергә һәм тизрәк поликлиникадан табиб чакыртырга кирәк булачак.

Коронавирус кеше организмында зур активлыкка ия булуын күрсәтте. Эпидемия башланган чорда табиблар әле аның кешедән-кешегә күчү сәләте бу кадәр югары булыр дип уйламаган иде. Ә вирус мутацияләнеп, тормышта үз урынын яулап алды. Кызганыч, ләкин  шактый вакыт узса да, сакланырга таләп ителә. Бу вакытта, әгәр йорттан чыгарга туры килсә, **битлек һәм перчаткалар кияргә**. Кулларны даими юарга,1,5 метр аралыкны тотарга, күзләргә, колак һәм танауга кул белән тимәскә тырышырга, чирнең тәүге билгеләре сизелү белән **башкалардан аралanырга**. Әгәр тынıгыз кысыла башласа һәм коры ютәл башланса – табибны чакырыгыз. Шуңа күрә, укучылар, югарыда китерелгән таләпләрне үтәргә кирәк. Юкса үзебез өчен нәтиҗәсе куркыныч булуы мөмкин.

***Мөхәррир Фәнүзә Гафиятуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

*/Рәсми хәбәрләр /*


## *II яртыеллык нәтиҗәләре*

19 нчы март көнне уку елының иң озын өченче чиреге тәгәлләнде. Пандемия сәбәпле, язгы каникуллар берничә көнгә алданрак башланды. Барыбыз да ел саен яратып көтеп алган Нәүрүз бәйрәме белән мәктәп ярминкәсе дә уздырылмады. Уку нәтиҗәләрнеә килгәндә, мәктәптәге 54 укучының 39ына чирек билгеләре чыгарылды. Чирекне гел бишле билгеләренә  – өченче сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил**, 9 нчы сыйныфтан **Әхмәтова Нәзирә** тәгәлләде. Тагын 21 укучы дүртле - бишле билгеләренә генә өлгерде. Шулай итеп, гомуми нәтиҗәләр буенча, белем сыйфаты **59 %** тәшкил итте. Язгы каникуллар 20 нче марттан 6 нчы апрельгә кадәр дәвам итте.

Уку елының IV чиреге, гадәттәгедән аермалы буларак, дистанцион уку белән барды. Мондый төр уку укучы, укытучы өчен дә, әти-әниләр өчен дә көтелмәгән булганга күрә, берникадәр кыенлыклар тудырды. Эш режимы үзгәрүгә карамастан, уку-укыту планнары үтәлергә тиеш иде. Бакча төркеме үз-үзеңне изоляцияләү көннәре тәгәлләнгәннән соң гадәти тәртип белән эшләвен дәвам итте.

Еллык нәтиҗәләрне дә онлайн укыткан белем сыйфаты буенча билгеләдек. Уку елының соңгы чиреге берникадәр югарырак нәтиҗәләр бирде. Мәктәп күләмендә 9 укучы укуны “5” ле билгеләренә генә тәмамлады. IV чиректә укучыларның белем сыйфаты 61%, еллык нәтиҗәләр буенча уртача күрсәткеч 70,75% тәшкил итте.

***Илдар Сафиуллин, укыту эшләре буенча директор урынбасары***



## Читтән торып эшләп карадык

Пандемия сәбәпле быелгы елның 19 нчы апреленнән барлык мәктәпләр дә укытуның дистанцион формасына күчәргә мәҗбүр булды. Дистант форматына күчү барышында мәктәп укытучылары һәм укучылары шактый кыенлыклар белән очрашты. Цифрлы ресурслар белән эшли белү дәрәҗәсе эпидемиягә кадәр күпчелек укытучылар арасында бик югары түгел иде. Бары тик бик азлар гына бу төр укыту формасын өлешенчә кулланып килделәр. Әмма булган тәҗрибә дә бәяләү инструментларын һәм коммуникацион каналларны куллануны күздә тотмады. Бу бары тик олимпиада биремнәрен һәм өстәмә уку материалларын күчереп алуга гына кайтып калды. Шунлыктан, кыска вакыт эчендә яңа форматта эшләү, укыту алымнарын үзгәртеп корырга кирәклеге туганда, укытучыларның күбесе кыен хәлдә калды.

Уртача алганда, гадәти мәктәпләрдә дистанцион укуга күчү якынча 2 атна тәшкил итте. Беренче атна һәм алга таба да, укытучылар һәм укучыларның ни дәрәҗәдә әзерлексез булуын күрсәттеләр. Интернетка чыгу өчен кирәкле җайланмалар, веб-камералар, наушниклар булмау, авыл җирендә интернет тизлегенең тиешле дәрәҗәдә эшләмәве дә үзен нык сиздерде. Гаиләдә берничә бала булса, шәхси җайланмаларны бүлү дә аеруча авыр бурыч иде. Өйдәге барлык укытучыларның да шәхси эш урыны юк, күпләргә дәресләр үткәрү өчен өй киңлеген бик нык үзгәртергә, аларның хәленә кергән өйдәгеләрне шактый кысрыкларга туры килде. Өстәвенә, дистанцион укыту форматында эш көне шактый артты, бу укытучылар өчен өстәмә авырлык китерде.

Дистанцион укытуга күчү шулай ук белем бирү платформаларының (“Российская электронная школа” («РЭШ»), «Учи.ру», «Яндекс учебник», «ЯКласс», «WhatsApp», «В Контакте», “zoom”) эше белән бәйле кайбер проблемаларны да ачыклады. Аларның күбесе бик авыр эшләде, шуның аркасында мәктәпләргә сыйныфларны аларга тоташтыру графикларын төзергә туры килде. Шуның өстенә платформалардан алган материаллар күп очракта пандемиягә кадәр кулланылган уку-укыту программаларына бик аз туры килде. Укытучыларга, беренче чиратта, укучылар белән тере элемтә җитмәде. Шунлыктан, укытучыларга балаларның катнашуын һәм җәлеп ителүен күзәтеп тору, дискуссияләр кору һәм проблемалы мәсьәләләр буенча фикер алышу катлаулырак булды.

IV чиректә мәктәпләрдә дистанцион укытуның төп нәтиҗәсе шул булды – балаларга сыйфатлы белем бирү укытучы белән укучының тере аралашуыннан башка мөмкин түгел. Бу беренче чиратта башлангыч һәм урта буын сыйныф укучыларына кагыла. Шуңа да карамастан, укытучылар катнаш укыту моделенең (онлайн һәм офлайн-форматтагы комбинацияләрнең) киләчәге бар дип таныйлар. Һәрхәлдә, алар фикеренчә моны замана таләп итә.

***Илдар Сафиуллин, укыту эшләре буенча директор урынбасары***

## Мәктәп бакчасында язгы эшләр



Дөнья буйлап таҗлы вирус таралуга карамастан, табигать үз кануннары белән яши. Быелгы яз чагыштырмача иртә һәм җылы килде. Туфраклар өлгергәч, яшелчәләр утыртырга да вакыт җитте. Балалар укырга йөрмәсәләр дә, мәктәп хезмәткәрләре белән бакчага үзебезгә җитәрлек күләмдә кишер, суган, чөгендерләр утырттык. Ир-ат хезмәткәрләр яшелчә бакчасы өчен уңайлы капка ясап куйдылар.

Җиңүнең 75 еллыгы хөрмәтенә мәктәп бакчасына 75 төп чия куагы утыртылды. Үсентеләрне мәктәпкә җирле идарә башлыгы Хөснуллина Энҗе бүләк итте. Әлеге игелекле эше өчен аңа зур рәхмәтләр белдерәбез.

Май уртасында бәрәңге утыртылды. Мәктәпнең бәрәңге бакчасын үз техникасы белән Морадимов Рафис абый эшкәртеп бирде. Авылның җәмәгать эшләрендә даими булышып торганы өчен мәктәп коллективы исеменнән аңа да зур рәхмәтләребезне җиткерәбез.

***Мәктәп бакчасы мөдире Рифкать Туктамышев, биология укытучысы***





## Бәйрәмнәрдән башка күңелсез шул

Илдә карантин кертелү сәбәпле, мәктәпләрдә уку гына түгел, күп халык катнаша торган күмәк чаралар үткәрү дә тыелды. Шул сәбәпле, ел саен шау-гөр килеп үткәрелә торган Нәүрүз бәйрәме, мәктәп ярминкәсе, язгы сахрага чыгулар уздырылмыйча калды. Уку елы “Соңгы кыңгырау”сыз гына тәгәлләнгәч, күңелдә әллә нинди уңайсыз хисләр калды. Алдагы елларда һәрвакыт нindидер үзенчәлекле чаралар белән уза торган гает бәйрәме дә үткәрелмәде. Илдә нинди генә үзгәрешләр булса да, безне халкыбызның бәйрәмнәре, мәдәниятебезнең кыйммәте булган рухи байлыклары аша кече Ватаныбызга карата мәхәббәт тәрбияләгән өлкәннәребез Рамазан гаетеннән соң, һәр елдагыча балаларга мәчеттән бирелгән бүләкләр өләшенде. Тәмле гает бүләкләре өчен мәчеткә йөрүче абыйларга һәм бабайларга зур рәхмәт.

***Зөлфирә Сафиуллина, VIII сыйныф укучысы***

**/Бөек Җиңүнең 75 еллыгына/**

## *Авылдышыбыз – полк командиры*


Бөек Ватан сугышында катнашкан 160тан артык авылдашыбызның җидесенең офицер званиесында булганлы билгеле. Шулар арасында иң югары хәрби дәрәҗәгә ия булган кыю командир **Хөснуллин Хәбибулла Хөснулла улы** аерым урын били. Кызганыча каршы, Хәбибулла бабайның тормыш юлына кагылышлы хәбәрләребез бик күп түгел. Ул 1905-нче елның 14 февралендә Әхмәтҗанов Хөснулла бабай гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килә. Армиягә алынганнан соң, ул тормышын хәрби хезмәткә багышлый. 1927-нче елдан алып Кызыл Армиядә кадровый хәрби санала. 1931-нче елда кече командир званиесында Төркстанда басмачыларга каршы сугышларда катнаша. 1933-нче елда хәрби училищены тәмамлап офицер дәрәҗәсе ала.



Хөснуллин Хәбибулла Бөек Ватан сугышының беренче көненнән үк катнаша. Бу вакытта ул майор званиесында була. Авыл картлары сөйләве буенча, Хәбибулла бабай 1941-нче елны Лаешта полк оештырып, шуның белән фронтка киткән. Документаль чыганаклардан Хәбибулла абыйның 1941-нче елның 8 сентябрендә Төньяк-Көнбатыш фронтта сугышканда беренче тапкыр яраланганы билгеле.

1942-нче елның ноябреннән алып майор Хөснуллин Үзәк фронтта 70-нче армия составындагы 132-нче укчы дивизиянең 712-нче полкында полк командиры урынбасары булып хезмәт итә. 1943-нче елның июлендә Курск дугасында барган сугышларда полк белән оста идарә иткәне һәм шәхси батырлыгы өчен **1-нче дәрәҗә “Ватан сугышы” ордены** белән бүләкләнә.

1943-нче елның ноябрендә, подполковник званиесы алганнан соң, Хөснуллин Хәбибулла 253-нче укчы дивизия составындагы **979-нчы укчы полкы командиры** итеп билгеләнә. 1944-нче елның гыйнвар башында немец гаскәрләренең эре оборона үзәге булган Озаричи поселогын (Гомель өлкәсендә) аз югалтулар белән азат иткәне өчен **3-нче дәрәҗә Кутузов ордены** белән бүләкләнә.



***Луцк шәһәрендәге мемориаль туганнар каберлеге***

1944-нче елның язында Хәбибулла бабайга чираттагы полковник званиесы бирелә. Бу вакытта ул Көнбатыш Украинаны азат итү сугышларында катнаша. 17-нче июль көнне дошманның Волын өлкәсе Сенкевичи районындагы көчле ныгытылган оборона линияләрен өзгәндә үзе сугышчыларын атакага алып бара. Әлеге һөҗүм полковник Хөснуллинның соңгы сугышы була. Снаряд кыйпылчыгыннан авыр яраланып ул 29-нч август көнне госпитальдә вафат була. Үлгәннән соң Хәбибулла бабай тагын бер **1-нче дәрәҗә “Ватан сугышы” ордены** белән бүләкләнә. Башта аны шул Сенкевич районындагы Загайник авылы зиратына җирлиләр. Соңрак мәете Луцк шәһәре үзәк паркындагы 900 сугышчы күмелгән мемориаль туганнар каберлегенә күчерелә.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***




## *Җиңү көне чаралары*

Ел башыннан ук планлаштырылса да, Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын зурлап бәйрәм итү мөмкин булмады. Шуңа да карамастан, 9 май иртәсендә 9 сыйныф укучылары Нурматов Халит белән Панов Артур, елдагы гадәт буенча, һәйкәл каршына сакка бастылар. Узган еллардан аермалы буларак, сакта торган егетләр чын сугыш чоры солдатлары киемнәрен киеп, ППШ автоматы, СКС-45 карабины белән чыктылар. Аларны безнең мәктәпкә Чаллы шәһәрендә яшәүче күренекле авылдашыбыз Хафизов Фаиз абый бүләк итте. Шундый зур һәм истәлекле бүләкләре өчен Фаиз абыйга барлык укучылар исеменнән олы рәхмәтебезне җиткерәбез.

Һәйкәлгә венок чыгарылганнан соң ветераннар советы рәисе Гафиятуллин Госман бабай сугыштан кайтмаган авылдашлар рухына багышлап дога кылды. Бәйрәм чаралары шуның белән тәгәлләнде.

***Сара Насыйрова, IX сыйныф укучысы***

*/Күренекле шәхесләр/*



## *Мәдәни гаилә*

Иске Татар Әдәмсуында яшәүче Морадимовлар гаиләсен безнең авыл җирлегендәге иң мәдәни гаилә дисәк тә ялгышмабыз. Җирлектә һәм районда үткәрелә торган бер генә мәдәни чара да алар катнашыннан башка узмый.

Быелгы яз, пандемия сәбәпле, мәдәни чараларга бай булмаса да, дистанцион рәвештә уздырыла торган төрле конкурслар булып торды. Мөмкинлекләрдән чыгып, без дә аларда катнашырга тырыштык. Шулардан иң зур чара – Габдулла Тукайның туган көненә багышланган **“Тукай безнең йөрәкләрдә”** конкурсы булды. “Без гаиләбез белән Тукайны укыйбыз” номинациясендә 10-нчы сыйныф укучысы Морадимов Илназ гаиләсе белән видеоролик ясап җибәрде. Аны интернет киңлегендә инстаграмга “Родные рифмы” # хэштегына элдек. Анда да күп караучылар таптык. Бу чарага чын күңелен биреп әзерләнгән Илназның әнисе Морадимова Гөлнарага зур рәхмәтләребезне әйтәсебез килә. Тукай шигырьләрен укудан Венера әби дә, әтиләре Разыйм да, 7-нче сыйныфта укучы энесе Илсур да читтә калмады. Әлбәттә, күңелеңне биреп эшләгән эш игътибарсыз калмый. Шулай итеп, Морадимовлар гаиләсе I урынга чыкты һәм мәгариф бүлеге тарафыннан грамота белән бүләкләнде. Аларны бу җиңүләре белән котлап, мәктәп коллективы исеменнән рәхмәт белдерәбез.

Дистантка күчер алдыннан 10-нчы мартта **“Телләр төрле – йөрәкләр бердәм”** республика бәйгесенең муниципаль туры уздырылган иде. Бу чарага да нык әзерләнеп, республикага чыгу максаты белән бардык. Бәйгедә Илназ Әнгам Атнабаевның “Туфрак” дип аталган шигыре белән чыгыш ясап җиңү яулады һәм республика турында катнашу мөмкинлеген алды.

Быел 10-нчы сыйныфта укучы Илназ Мордимов, мәктәпне тәмамлаганнан соң, мәдәният юнәлеше буенча укырга керергә һәм хезмәт юлын шул юнәлешкә багышларга җыена. Без аңа теләкләренең чынга ашуын телибез, ә гаиләсенә алдагы елларда да зур иҗади уңышлар теләп калабыз.

***10-нчы сыйныф җитәкчесе Фәнүзә Гафиятуллина***

## *Онлайн шахмат турниры*

*/Безнең спорт/*

Бөек Җиңүнең 75 еллык юбилеен Аксубай районы шахматчылары да зурлап билгеләп үтте. Укыту процессы кебек үк барлык төр спорт уеннары онлайн режимга күчерелү сәбәпле, турнир да компьютер ярдәмендә узды. Мәктәбебезнең яшь шахматчысы Гафиятуллин Фаил дә әлеге бәйрәмгә үз өлешен кертеп, төрле яшьтәге Аксубай муниципаль районы шахматчылары арасында үткән онлайн шахмат турнирында 2 урын яулады. Фаил грамота һәм медаль белән бүләкләнде. Киләчәктә дә аңа зур уңышлар телибез!!!

*/Күңелле тәнәфес/*

## *Табышмак әйтәм – тап*

Өй артында озын агай
Энә белән кое казый.

Ут та түгел, ук та түгел,
Күзгә төшә, карны кисә.

Көн туганчы көн итә,
Үлән башын су итә.

Башы тауда, аягы диңгездә.

Елмый агай елмаеп боз эретә.

Иелә дә бөгелә,
Ак мамыгы түгелә,
Кара күзе күренә.

Колга башында йорты,
Эчендә яши җырчы.

*/Котлыйбыз!/*



Хөрмәтле укытучыларыбыз Туктамышев Рифкать (10-нчы апрель) һәм Сафиуллин Илдар (16-нчы апрель) абыйларны, Иванова Олеся (14-нче апрель) һәм Хәйруллина Рузилә апаларны (24 нче май) туган көннәре белән котлыйбыз. Сезгә сәламәтлек, гаилә бәхете, эшегездә уңышлар теләп калабыз.

Яз айларында туган көннәре булган укучылар – III сыйныфтан Залиева Вәсилә (12-нче апрель), VII сыйныфтан Морадимов Илсур (3-нче март), VIII сыйныфтан Сафиуллина Зөлфирә (2-нче март), Туктамышева Әминә (17-нче май), Хәбибрахманов Ильяс (24-нче май), IX сыйныфтан Гыйззәтуллина Алия (11-нче март), X сыйныфтан Шафиков Әнис (4-нче март), Шәрифуллин Илсаф (11-нче апрель), Морадимов Илназларны (24-нче апрель) чын күңелдән тәбрик итәбез, ныклы сәламәтлек, укуларында уңышлар телибез.

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:**
Әминә Туктамышева, Алия Гыйззәтуллина
Виктория Нукина, Нәзирә Әхмәтова
Зөлфирә Сафиуллина, Рузилә Мөхәмматова
Сара Насыйрова